МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.05.2021 Казан ш. № 21-53-131

Татарстан Республикасы бюджетыннан
җирле бюджетларга бирелгән
файдаланмаган
кредитларның калган
өлешләрен түләтү тәртибе

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{3}$ маддәсенең 4 пункты нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән файдаланмаган кредитларның калган өлешләрен түләтү тәртибен расларга.
2. «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән файдаланмаган кредитларның калган өлешләрен түләтү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2008 елның 23 июлендәге 21-53-59 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә ~~алу өчен~~ җибәрергә.
4. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
2021 елның «24» маеннан 21-53-131
номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән файдаланмаган кредитларның калган өлешләрен түләтү тәртибе

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән файдаланмаган кредитларны калган өлешләрен түләтүнең әлеге тәртибе, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән процентларны, штрафларны һәм пеняларны да кертеп, файдаланмаган бюджет кредитларының калган өлешләрен (алга таба - Тәртип, файдаланылмаган кредитларның калган өлешләрен) түләтү кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (алардан файдалану, кире кайтару) тәртибен раслау турында" 2010 елның 29 гыйнварындагы 44 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибендә каралган срокта Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитын капланмаган очракта, аларны түләтүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Файдаланмаган кредитларның калган өлешләрен түләтү җирле бюджетка Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр исәбеннән, шулай ук җирле бюджетка күчерелергә тиешле федераль һәм региональ салымнар һәм җыемнардан, махсус салым режимнарында каралган салымнар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Түләү процедурасын башкару өчен документлар исемлеге:

а) бюджет кредиты бирү турында шартнамә;

б) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының анализ һәм стратегия бүлеге (алга таба - анализ һәм стратегия бүлеге) тарафыннан әзерләнгән файдаланмаган кредитның калган өлешләрен булуы турында белешмә.

5. Бюджет кредитын кире кайтару срогы килеп җитү көненнән алып биш эш көне эчендә анализ һәм стратегия бүлеге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Төбәк бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлегенә (алга таба – төбәк бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге) әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны җибәрә.

Төбәк бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге документлар килеп ирешкән көннән алып җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы финанс министрына файдаланмаган кредитның калган өлешләре булган җирле бюджетның үтәлеше турында белешмә мәгълүмат әзерли.

6. Файдаланмаган кредитның калган өлешләрен кайтару турындагы карар җирле бюджетның үтәлеше турында белешмә мәгълүмат бирелгән вакыттан алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы формасында (алга таба - боерык) кабул ителә.

7. Файдаланмаган кредитның калган өлешләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр исәбеннән түләтү турында боерык чыгарылган очракта, төбәк бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге биш эш көне эчендә муниципаль районнарның (шәһәр берәмлекләренең) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр буенча бюджет ассигнованиеләрен үзгәртү (киметү) турында хәбәрнамә әзерли һәм аны Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет бүлегенә җибәрә.

8. Файдаланмаган кредитның калган өлешләрен җирле бюджетка күчерелергә тиешле федераль һәм региональ салымнар һәм җыемнардан, махсус салым режимнарында каралган салымнар исәбеннән түләттерү турында боерык чыгарылган очракта, анализ һәм стратегия бүлеге аны бастырган көннән алып җиде эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2020 елның 13 апрелендәге 67н номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан һәм җирле бюджетлардан бирелгән кредитларның файдаланмый калган өлешен түләтү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан һәм җирле бюджетлардан түләнмәгән кредитларның файдаланылмый калган өлешен түләтү тәртибенә гомуми таләпләргә кушымтага ярашлы рәвештә төзелгән Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән файдаланмаган кредитның калган өлешен түләтү турындагы карарны (алга таба - Карар) Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенә җибәрә.

Дәүләт серен тәшкил итмәгән белешмәләре булмаган карар «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында электрон документ рәвешендә төзелә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы исеменнән эш итәргә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм «Электрон бюджет» системасын кулланып Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта җибәрелә.

Карарны формалаштырганда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 30 июнендәге 658 номерлы карары белән расланган «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасы турындагы Нигезләмә нигезендә барыла торган классификаторлар, исемлекләр һәм белешмәләр кулланыла.